**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 1 март № 123

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 9 июнь, 453 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 май, 379 нчы; 2011 ел, 9 август, 645 нче; 2012 ел, 29 ноябрь, 1045 нче; 2013 ел, 12 март, 158 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 812 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 918 нче; 2015 ел, 23 июнь, 457 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 790 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 423 нче; 2016 ел, 13 август, 558 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.14 пунктчада «керә торган» сүзләрен «кергән» сүзенә алмаштырырга;

3.3.17 пунктчага түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы шаһәдатнамәләр бланкларына татар телендә мәгълүматлар кертүне тәэмин итә.»;

3.3.20 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2015 елның 1 апреленә кадәр төзелгән граждан хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләреннән җыелган һәм әлеге граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алган урын буенча граждан хәле актларын язу органнарында сакланган граждан

хәле актларын дәүләт теркәвенә алу китапларын (актлар китапларын), Граждан хәле актларын язу буенча бердәм дәүләт реестрын формалаштыру максатларында, электрон формага күчерү эшләрен башкаруны тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\123.doc